РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 29 мае № 22

**Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы:

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә, карарга кушымтаның 1 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин

Түбән Кама шәһәр Советының
2023 елның 29 маендагы
22 номерлы карарына кушымта

Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) кертелә торган үзгәрешләр

1. Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 1.2 пунктында:

1 абзацны «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар белән» сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга таләпләр.»

2. Нигезләмәнең 5 бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 5.1 бүлекчә белән тулыландырырга:

«5.1 Судка кадәр шикаять бирү

5.1.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында, аларның фикеренчә, хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдә тотылучы затлар Контроль органы җитәкчесе һәм инспекторларның (алга таба шулай ук - вазыйфаи затлар) түбәндәге карарларына судка кадәр шикаять бирү хокукына ия:

1) контроль чаралар үткәрү турында карарлар;

2) контроль чаралар актлары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр;

3) контроль чаралар кысаларында вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмаулары).

5.1.2. Шикаятьне контрольдә тотылучы зат, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очрактан тыш, электрон рәвештә Контроль органына бирә.

Граждан шикаять биргәндә, ул гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Оешма шикаять биргәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаятькә теркәлгән материаллар, шул исәптән фото һәм видеоматериаллар, контрольдә тотылучы зат тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла.

5.1.3. Контроль органы карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан карала.

5.1.4. Контроль (күзәтчелек) органы карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдә тотылучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Контроль органы күрсәтмәсе буенча шикаять контрольдә тотылучы зат күрсәтмәне алганнан соң ун эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

5.1.5. Әгәр дә шикаять бирү вакыты җитди сәбәпләр аркасында узып китсә, шикаять бирүче контрольдә тотылучы затның үтенече буенча бу срок Контроль органы тарафыннан торгызыла ала.

5.1.6. Шикаять биргән контрольдә тотылучы зат, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

5.1.7. Шикаятьтә Контроль органының шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенеч булырга мөмкин.

5.1.8. Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) шикаять теркәлгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул итә:

1) Контроль органының шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органының шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында.

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат шикаять биргән контрольдә тотылучы затка карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә җибәрелә.

5.1.9. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) аларның карары һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган Контроль органының атамасы, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында мәгълүмат, яисә контрольдә тотылучы затның оешмасы атамасы, әлеге оешманың урнашу урыны турында мәгълүмат, яисә ышаныч кәгазе реквизитлары һәм ышаныч кәгазе буенча шикаять бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне караган вакытта үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карар алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдә тотылучы затның хокукларын бозуга китергән яки китерергә мөмкин булган Контроль органының шикаять бирелгән карарлары һәм (яки) аның вазыйфаи затының гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) контрольдә тотылучы затның Контроль органы карары һәм (яки) вазыйфаи затның гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәгән нигезләре һәм дәлилләре. Контрольдә тотылучы зат тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тәкъдим ителә ала;

5) шикаять биргән контрольдә тотылучы затның таләпләре;

6) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте башканы билгеләмәсә, аңа карата шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында контроль чараның исәп номеры.

5.1.10. Шикаятьтә әдәпсез яки мыскыллаучы сүзләр, Контроль органының вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата янау булырга тиеш түгел.

5.1.11. Шикаять бирү, аңа тиешле хокукны «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тапшырган очракта, контрольдә тотылучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырыла ала.

5.1.12. Контроль органы шикаятьне караудан баш тарту турында карарны шикаять алынган көннән алып биш эш көне эчендә кабул итә, әгәр:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 4.3.4 пунктында билгеләнгән шикаять бирү срогы тәмамланганнан соң бирелгән булса, һәм шикаять бирү өчен узган срокны торгызу турында үтенеч язуы булмаса;

2) шикаять бирү өчен узган срокны торгызу турында үтенечне канәгатьләндерүдән баш тартылса;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны биргән контрольдә тотылучы заттан шикаятьне кире алу турында гариза кергән булса;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары бар;

5) элегрәк Контроль органына шул ук контрольдә тотылучы заттан шул ук нигезләр буенча башка шикаять бирелгән булган;

6) шикаятьтә әдәпсез яки мыскыллаучы сүзләр, Контроль органының вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата янау бар;

7) элек шул ук предмет буенча шикаятьне караудан баш тартылган, бу әлеге контрольдә тотылучы затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген кире кага, һәм яңа дәлилләр яки шартлар китерелми;

8) шикаять тиешле булмаган органга тапшырылган;

9) Россия Федерациясе законнары белән Контроль органы карарларына шикаять бирүнең суд тәртибе генә каралган.

5.1.13. Әлеге Нигезләмәнең 4.3.12 пунктының 3-8 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаятьне карау нәтиҗәсе түгел, һәм Контроль органы карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка шикаять бирү өчен нигез булып хезмәт итә алмый.

5.1.14. Шикаятьне караганда, Контроль органы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмати системасын алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмати системасын куллана.

5.1.15. Шикаять теркәлгәннән соң егерме эш көне эчендә Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан каралырга тиеш.

5.1.16. Күрсәтелгән срок түбәндәге очракларда егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

1) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелгән вазыйфаи затка карата шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча хезмәт тикшерүе уздыру;

2) җитди сәбәпләр аркасында (авыру, отпуск, командировка) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелгән вазыйфаи затның булмавы.

5.1.17. Контроль органы шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорарга хокуклы. Контрольдә тотылучы зат әлеге мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау вакыты шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында сорату җибәрелгәннән алып, аларны вәкаләтле орган алганчыга кадәр, әмма сорату җибәрелгәннән соң биш эш көненнән артмаган вакытка туктатып торыла.

Контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар алмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

5.1.18. Шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынган оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документлар сорарга ярамый.

Шикаять биргән зат, шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче, үз теләге буенча шикаять предметына кагылышлы өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

5.1.19. Кабул ителгән карарның һәм (яки) башкарылган гамәлнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы Контроль органына йөкләнә.

5.1.20. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль органы карарын тулысынча яки өлешчә гамәлдән чыгара;

3) Контроль органы карарын тулысынча гамәлдән чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип таный һәм, асылда, шул исәптән кирәк булганда билгеле бер гамәлләрне тормышка ашыру турында карар чыгара.

5.1.21. Контроль органының кабул ителгән карарны нигезләүне, аны үтәү срогын һәм тәртибен үз эченә алган карары контрольдә тотылучы затның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындагы һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләрнең төбәк порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары М.В. Камелина